Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында

ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Иске Тәрбит авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1. Шәһәр төзелеше регламентлары;
2. Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы;
3. Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зона картасы;
4. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен куллану һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе.

Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:

1. Гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләнең асылы буенча чыгышлар.
2. Гавами тыңлауларда катнашучыларның сорауларын һәм тәкъдимнәрен карау.

Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга барлык чыгышлар тәмамланганнан соң сораулар бирергә хокуклы. Сораулар һәм тәкъдимнәр язма рәвештә бирелә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы: 2025 елның 09 декабреннән 2025 елның 18 декабренә кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе: Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты, җир кишәрлеге урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шушы территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, шундый җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы:

-Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге;

Татарстан Республикасы, Кайбыч районы Иске Тәрбит авылы, Совет ур., 28 й. адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Соравыл ав.., Үзәк ур., 45 й.;
- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Камыллы ав., Совет ур., 26 й..

Экспозициягә (экспозицияләргә) бару мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: 2025 елның 16-17 декабрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, 2025 елның 18 декабрендә 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр.

Проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше: проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2025 елның 09 декабреннән 2025 елның 17 декабренә кадәр 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, 2025 елның 18 декабрендә 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр язма рәвештә кабул ителә:

-Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә;

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы Иске Тәрбит авылы, Совет ур., 28 й. адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлеге Башкарма комитетында.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат 2025 елның 18 декабрендә:

- 13.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Кайбыч районы Иске Тәрбит авылы, Совет ур., 28 й. адресы буенча күп функцияле үзәк бинасында;
- 14.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Соравыл ав.,, Үзәк ур., 45 й. адресы буенча күп функцияле үзәк бинасында.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат: Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтының «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлеге (http://kaybici.tatarstan.ru).

Әлеге хәбәрне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм:

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й. адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк;
- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы Иске Тәрбит авылы, Совет ур., 28 й. адресы буенча күп функцияле үзәк бинасы;
- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Соравыл ав.,, Үзәк ур., 45 й. адресы буенча күп функцияле үзәк бинасы;
- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Камыллы ав., Совет ур., 26 й. адресы буенча урнашкан кибет мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Н. Макаров